**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

алтынчы утырыш
**КАРАРЫ**

29 нчы декабрь 2020 ел **№ 31** Теләче авылы

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2013 елның 28 октябрендә кабул ителгән 170 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын раслау һәм аның хезмәткәрләренең чик санын билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының тәкъдимен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2013 елның 28 октябрендә кабул ителгән 170 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын раслау һәм аның хезмәткәрләренең чик санын билгеләү турында» карарына (19.12.2013 № 188, 26.05.2014 № 212, 27.11.2014 № 234, 17.04.2015 № 263, 22.04.2016 № 47, 12.04.2018 № 128, 24.08.2018 № 142, 28.03.2019 № 172, 21.08.2019 №186, 18.09.2019 №193, 20.11.2019 № 208, 20.01.2020 №225, 23.09.2020 № 7 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасыннан түбәндәндәге муниципаль хезмәт вазыйфаларын чыгарырга: район Башкарма комитетының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, район Башкарма комитетының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының баш белгече, район Башкарма комитетының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы баш белгече.

1.2. Карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләренең иң чик санын 32 штат берәмлегендә билгеләргә.».

1.3. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы Н.Н. Хаҗипов

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2020 елның 29 нчы декабреннән булган 31 нче номерлы карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасы

